СОВЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 52, с. Старое
Чурилино,
Арский муниципальный район,
422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 52 йорт, Иске Чүриле
авылы,
Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48,3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Shur.Ars@tatar.ru

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**01.11.2016 ел** **№ 26**

**Җир салымы турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге Уставына таянып, Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2017 елның 1 гыйнварыннан Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә әлеге территориядә мәҗбүри түләүгә җир салымы билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Җир салымының кадастр бәясеннән салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:
- гомуми файдаланудагы 1 - 3 категорияле автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05 процент;
- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллану зоналары составындагы җирләргә карата 0,3 процент;
- Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент;
- торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлегенә карата 0,1 процент;
- шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент;
- җитештерү биналарын, төзелешләрен, сәнәгать корылмаларын, коммуналь хуҗалык корылмаларын урнаштыру, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, торак пунктлар җирләре составында сату һәм әзерләү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,2 процент;
- Башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 процент.
3. Салым ташламаларын түбәндәгечә калдырырга:
3.1. 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

- муниципаль учреждениеләргә - мәйданнар, урамнар, машина юллары, автомобиль юллары, яр буйлары, парклар, аллеялар, скверлар белән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата;

- оешмаларга һәм учреждениеләргә - зиратлар, үләт базлары, граждан күмүләре, каты көнкүреш калдыклары полигоннары белән җир кишәрлекләренә карата;

3.2. Җир салымын түләүдән өлешчә азат итү рәвешендә:

- федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан финанслана торган Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте һәм идарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә җирнең кадастр бәясенең 0,6 проценты күләмендә киметелгән салым ставкасын куллану рәвешендә;

3.3. Шәхси ярдәмче хуҗалык өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата салым түләүдән салым түләүчене сайлау буенча бер җир кишәрлеге өчен тулысынча азат итү рәвешендә:

- ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә салым чоры дәвамында ирекле янгын сүндерү командалары (дружиналар) составында янгыннарны сүндерүдә турыдан-туры катнашу шарты белән.

4. Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә салым базасын киметү хокукын раслый торган документлар салым салу объекты буларак таныла торган җир кишәрлегенең урнашкан урыны буенча салым органына тапшырыла дип билгеләргә. Салым базасын киметү хокукын раслый торган документларны тапшыру срогы - узган салым чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр.

Салым базасын киметүгә хокук барлыкка килгән (туктатылган) очракта, әлеге хокукның барлыкка килүен (туктатылуын) раслый торган документлар салым түләүчеләр тарафыннан ул барлыкка килгән (туктатылган) көннән алып 30 көн эчендә тапшырыла.

5. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Салым чоры дип календарь ел танылa.

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы танылa.

Салым түләүчеләр - салым түләү оешмалары өчен җир кишәрлегенең кадастр бәясенең беренче, икенче һәм өченче квартал узганнан соң икенче айның 15 көненнән дә соңга калмыйча кадастр бәясенең процент ставкасы күләмендә аванс түләүләре башкарыла. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

6. Әлеге карар Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә «Арча хәбәрләре» район газетасында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

7. Иске Чүриле авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында” 11.11.2015 ел, № 8 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Заһидуллина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СТАРОЧУРИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ОГРН1121690018197 ИНН1609012646
СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ